**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2025 елның «22» декабреннән № 287

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021-2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 11 декабрендәге 323 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә физик культура һәм спорт турында» 2007 елның 4 декабрендәге 329-ФЗ номерлы Федераль закон, «Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль программасын раслау турында» 2020 елның 11 декабрендәге 323 номерлы карары белән расланган (2021 елның 25 мартындагы 145 номерлы, 2021 елның 08 июлендәге 281 номерлы; 2021 елның 23 августындагы 344 номерлы; 2021 елның 20 декабрендәге 525 номерлы, 2022 елның 21 мартындагы 80 номерлы, 2022 елның 30 июнендәге 181 номерлы, 2023 елның 16 мартындагы 76 номерлы, 2023 елның 06 июлендәге 155 номерлы, 2024 елның 11 мартындагы 101 номерлы, 2024 елның 19 июлендәге 197 номерлы, 2025 елның 08 апрелендәге 93 номерлы, 2025 елның 03 июнендәге 132 номерлы, 2025 елның 08 сентябрендәге 183 номерлы, 2025 елның 24 ноябрендәге 254 номерлы үзгәрешләр белән) «2021 - 2025 елларга Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында физик культураны һәм спортны үстерү» муниципаль

программасына (алга таба - Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлегендә 2025 елга җирле бюджеттына «300,556» санын «300,846» санына алыштырырга.

«Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» бүлегендә 2025 елга республика бюджетына түбәндәге эчтәлекле сүзләрне өстәргә: «2025 ел - 28,99 мең сум (аутсортинг)»;

Программаның 6 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

Күрсәтелгән учреждениеләрдә спорт төрләре буенча шөгыльләнүче спортчыларны әзерләү һәм йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләре белән бәйле чыгымнары өлешендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү, 2025 елга финанс чыгымнары:

| | |
|---|---|
| Күрсәтелгән учреждениеләрдә спорт төрләре буенча шөгыльләнүче спортчыларны әзерләү һәм йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләре белән бәйле чыгымнары өлешендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү, финанс чыгымнары (республика бюджеты), сум | 28990,00 |
| Күрсәтелгән учреждениеләрдә спорт төрләре буенча шөгыльләнүче спортчыларны әзерләү һәм йөртү буенча аутсорсинг хезмәтләре белән бәйле чыгымнары өлешендә муниципаль хезмәтләр күрсәтү, финанс чыгымнары (җирле бюджет 1%), сум | 289,90 |

».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А.Л.Ерантьевка йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов